**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2015 ел, 26 ноябрь № 893

г. Казань

Югары патоген грипп вируслары һәм башка үтә көчле респиратор вируслы инфекцияләр, шул исәптән кош гриппы барлыкка китергән авыруларны Татарстан Республикасы территориясенә читтән кертүне һәм аларның таралуын кисәтү буенча комиссия төзү турында

Югары патоген грипп вируслары һәм башка үтә көчле респиратор вируслы инфекцияләр, шул исәптән кош гриппы таралуны кисәтү һәм Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары, Татарстан Республикасындагы федераль башкарма хакимият органнары территориаль органнарының, җирле үзидарә органнары һәм оешмаларның үзара хезмәттәшлеген тәэмин итү, профилактика чараларын һәм эпидемиягә каршы чараларны оператив рәвештә гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Югары патоген грипп вируслары һәм башка үтә көчле респиратор вируслы инфекцияләр, шул исәптән кош гриппы барлыкка китергән авыруларны Татарстан Республикасы территориясенә читтән кертүне һәм аларның таралуын кисәтү буенча комиссия төзергә.

2. Югары патоген грипп вируслары һәм башка үтә көчле респиратор вируслы инфекцияләр, шул исәптән кош гриппы барлыкка китергән авыруларны Татарстан Республикасы территориясенә читтән кертүне һәм аларның таралуын кисәтү буенча комиссия турындагы нигезләмәне һәм аның составын (карарга теркәләләр) расларга.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2006 ел, 13 март, 6-301 нче боерыгы үз көчен югалткан дип санарга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\893.docx

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2015 ел, 26 ноябрь, 893 нче
карары белән расланды

Югары патоген грипп вируслары һәм башка үтә көчле респиратор
вируслы инфекцияләр, шул исәптән кош гриппы барлыкка китергән авыруларны
Татарстан Республикасы территориясенә читтән кертүне һәм аларның таралуын
кисәтү буенча комиссия турында
нигезләмә

1. Югары патоген грипп вируслары һәм башка үтә көчле респиратор вируслы инфекцияләр, шул исәптән кош гриппы барлыкка китергән авыруларны Татарстан Республикасы территориясенә читтән кертүне һәм аларның таралуын кисәтү буенча комиссия (алга таба – Комиссия) югары патоген грипп вируслары һәм башка үтә көчле респиратор вируслы инфекцияләр, шул исәптән кош гриппы барлыкка китергән авыруларны Татарстан Республикасы территориясенә читтән кертүне һәм аларның таралуын кисәтү (профилактикалау) буенча Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары, Татарстан Республикасындагы федераль башкарма хакимият органнары территориаль органнарының, җирле үзидарә органнары һәм оешмаларның үзара хезмәттәшлеген оештыру һәм килешенгән гамәлләрен тәэмин итү максатларында төзелә.

2. Комиссия үзенең эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль конституцион законнарга, федераль законнарга, Россия Федерациясе Президенты һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте актларына, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына, Татарстан Республикасы Президенты һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты актларына, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таянып эш итә.

3. Комиссия турында нигезләмә һәм аның составы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.

4. Комиссиянең төп бурычлары түбәндәгеләр:

югары патоген грипп вируслары һәм башка үтә көчле респиратор вируслы инфекцияләр, шул исәптән кош гриппы барлыкка китергән авыруларны Татарстан Республикасы территориясенә читтән кертүне һәм аларның таралуын кисәтү (профилактикалау) буенча Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары, Татарстан Республикасындагы федераль башкарма хакимият органнары территориаль органнарының, җирле үзидарә органнары һәм оешмаларның килешенгән гамәлләрен әзерләү һәм тәэмин итү;

ведомствоара чараларны оештыру;

кирәк булган очракта, югары патоген грипп вируслары һәм башка үтә көчле респиратор вируслы инфекцияләр, шул исәптән кош гриппы барлыкка китергән авыруларны кисәтү (профилактикалау) өлкәсендәге Россия Федерациясе һәм

Татарстан Республикасы законнарын камилләштерү мәсьәләләре буенча тәкъдимнәр әзерләү.

5. Комиссия, үзенә йөкләнгән бурычларны үтәү максатларында, түбәндәге төп вазыйфаларны башкара:

Комиссия компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча материалларны һәм актлар проектларын оператив рәвештә әзерләү;

югары патоген грипп вируслары һәм башка үтә көчле респиратор вируслы инфекцияләр, шул исәптән кош гриппы барлыкка китергән авыруларны читтән кертүне һәм аларның таралуын кисәтүгә (профилактикалауга), шулай ук диагностикалау һәм дәвалауга юнәлдерелгән чараларны үткәрү мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары, Татарстан Республикасындагы федераль башкарма хакимият органнары территориаль органнарының, җирле үзидарә органнары һәм оешмаларның тәкъдимнәрен карап тикшерү;

Комиссия компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы Президентына һәм Татарстан Республикасы Премьер-министрына мәгълүмат бирү;

югары патоген грипп вируслары һәм башка үтә көчле респиратор вируслы инфекцияләр, шул исәптән кош гриппы барлыкка китергән авыруларны профилактикалау, диагностикалау һәм дәвалау өлкәсендә республика программаларын яки аерым чараларны әзерләү һәм гамәлгә ашыру мәсьәләләрен карап тикшерү;

югары патоген грипп вируслары һәм башка үтә көчле респиратор вируслы инфекцияләр, шул исәптән кош гриппы барлыкка китергән авыруларны читтән кертү һәм кисәтү (профилактикалау), диагностикалау һәм дәвалау мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары, Татарстан Республикасындагы федераль башкарма хакимият органнары территориаль органнарының, җирле үзидарә органнары һәм оешмаларның үзара хезмәттәшлеген, кирәкле кадрларны һөнәри әзерләүне һәм яңадан әзерләүне, грипп һәм үтә көчле респиратор вируслы инфекцияләргә эпидемиологик күзәтчелекне көчәйтүне, шулай ук профилактика чараларының, Татарстан Республикасы территориясендә грипп һәм үтә көчле респиратор вируслы инфекцияләр белән авырулар буенча эпидемик хәлне бәяләү һәм фаразлау нәтиҗәлелеген күтәрүне тәэмин итү;

югары патоген грипп вируслары һәм башка үтә көчле респиратор вируслы инфекцияләр, шул исәптән кош гриппы барлыкка китергән авыруларны Татарстан Республикасы территориясенә читтән кертүне һәм аларның таралуын кисәтүгә юнәлдерелгән, кабул ителгән карарларның гамәлгә ашырылуын даими тикшерүдә тотуны оештыру.

6. Комиссия түбәндәгеләргә хокуклы:

Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарыннан, Татарстан Республикасындагы федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан һәм оешмалардан Комиссия компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча билгеләнгән тәртиптә материаллар һәм мәгълүмат соратып алырга;

Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары, Татарстан Республикасындагы федераль башкарма хакимият органнары территориаль органнарының, җирле үзидарә органнары һәм оешмаларның вәкилләрен Комиссия компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча тыңларга һәм тиешле карарлар кабул итәргә;

мәнфәгатьле Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары, Татарстан Республикасындагы федераль башкарма хакимият органнары территориаль органнарының, җирле үзидарә органнары һәм оешмаларның, фәнни һәи иҗтимагый оешмалар вәкилләрен, шулай белгечләрне Комиссия эшенә билгеләнгән тәртиптә җәлеп итәргә;

Комиссия эшчәнлегенең төрле юнәлешләре буенча мәсьәләләрне хәл итү өчен эшче төркемнәр төзергә.

7. Комиссия утырышлары Комиссия әгъзалары тәкъдиме белән рәис карары буенча эпидемиологик хәлне исәпкә алып үткәрелә.

8. Комиссия карарлары ачык тавыш бирү юлы белән, утырышта катнашкан Комиссия әгъзаларының күпчелек тавышы нигезендә (утырышта катнашмаганнарның Комиссия рәисенә карар кабул итү өчен соңга калмыйча язмача яки электрон формада кертелгән фикерен исәпкә алып) кабул ителә. Тавышлар тигез булган очракта, утырышта рәислек итүче тавыш биргән карар кабул ителгән булып санала. Комиссия әгъзасы, кабул ителгән карар белән риза булмаган очракта, үзенең фикерен язмача бәян итәргә хокуклы, һәм әлеге фикер утырыш беркетмәсенә теркәп куелырга тиеш.

Комиссия утырышларында мәсьәләләрне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча карарлар кабул ителә, һәм алар утырыш беркетмәләре белән рәсмиләштерелә.

Утырыш беркетмәләренә Комиссия рәисе, ул булмаган очракта – утырыш үткәрү көнендә тиешле утырышны алып бару йөкләнгән Комиссия рәисе урынбасары яки Комиссия әгъзасы кул куя.

9. Комиссия компетенциясе нигезендә кабул ителгән карарлары, Комиссия утырышы беркетмәсен рәсмиләштергән көннән соң бер эш көненнән соңга калмыйча, гамәлгә ашыру өчен Комиссия әгъзаларына җибәрелә.

10. Комиссия эшчәнлеген оештыру-техник яктан тәэмин итү Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

___________________________

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2015 ел, 26 ноябрь, 893 нче
карары белән расланды

Югары патоген грипп вируслары һәм башка үтә көчле респиратор вируслы инфекцияләр, шул исәптән кош гриппы барлыкка китергән авыруларны Татарстан Республикасы территориясенә читтән кертүне һәм аларның таралуын кисәтү буенча комиссия составы

| | |
|---|---|
| Әхмәтов Марат Готыф улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры, комиссия рәисе |
| Вафин Адел Юныс улы | Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министры, комиссия рәисе урынбасары |

Комиссия әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Алиев Марс Шәриф улы | «Татптицепром» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Анфимова Алла Леонидовна | Татарстан Республикасы финанс министры урынбасары |
| Барышев Александр Георгиевич | Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре советы башкарма секретаре (килешү буенча) |
| Батков Федор Сергеевич | Татарстан Республикасы Хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм алардан файдалану идарәсе башлыгы |
| Гайнетдинова Лилия Әхәт кызы | Табигатьтән файдалану өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең (Росприроднадзор) Татарстан Республикасы буенча идарәсе җитәкчесе урынбасары (килешү буенча) |
| Гарәфиев Зөфәр Юныс улы | Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының Балигъ булмаганнар эшләре буенча участок полициясе вәкилләре һәм бүлекчәләре эшчәнлеген оештыру идарәсе башлыгы (килешү буенча) |
| Григорьева Елена Ивановна | Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе җитәкчесе урынбасары (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Егоров Андрей Вячеславович | Татарстан Республикасы транспорт һәм юл хуҗалыгы министры урынбасары |
| Зыятдинов Васил Билал улы | «Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча гигиена һәм эпидемиология үзәге» федераль бюджет сәламәтлек саклау учреждениесе баш табибы (килешү буенча) |
| Иванов Евгений Николаевич | Ветеринария һәм фитосанитария күзәтчелеге федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе җитәкчесе урынбасары (килешү буенча) |
| Кәримов Рәис Галимҗан улы | «Татар төбәкара ветеринария лабораториясе» федераль дәүләт бюджет учреждениесе директоры (килешү буенча) |
| Мостафин Айрат Рафинант улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Агросәнәгать комплексы, җир мөнәсәбәтләре һәм куллану базары идарәсе башлыгы |
| Никитин Андрей Иванович | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе башлыгы урынбасары |
| Орлов Андрей Николаевич | Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсе башлыгы урынбасары (килешү буенча) |
| Патяшина Марина Александровна | Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеген саклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе җитәкчесе (килешү буенча) |
| Перфилов Дмитрий Александрович | Федераль таможня хезмәте Идел буе таможня идарәсенең Татарстан таможнясы башлыгы урынбасары (килешү буенча) |
| Рассман Игорь Олегович | «Татарстан Республикасы предприятиеләре һәм эшкуарлары ассоциациясе» төбәк эш бирүчеләр берлеге генераль директоры урынбасары (килешү буенча) |
| Фәттахов Рашат Шакир улы | Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры урынбасары |

| | |
|---|---|
| Шәйхетдинова Любовь Николаевна | Сәламәтлек саклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органы җитәкчесе урынбасары (килешү буенча) |
| Шакиров Фәршат Сәгыйть улы | Федераль миграция хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе башлыгы урынбасары (килешү буенча) |
| Шакиров Фаяз Фәнил улы | Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгының Дәүләт экология күзәтчелеге инспекциясе башлыгы |
| Шакирова Гүзәл Рәис кызы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Сәламәтлек саклау, спорт һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру мәсьәләләре идарәсе башлыгы. |

F:\KARAR\2015\893.docx